КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 гыйнвар

г.Казань

№ 42

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларына һәм су биология ресурсларына кертелмәгән хайваннар дөньясы объектларын аулау тәртибен раслау турында» 2010 ел, 22 апрель, 293 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларына һәм су биология ресурсларына кертелмәгән хайваннар дөньясы объектларын аулау тәртибен раслау турында» 2010 ел, 22 апрель, 293 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 15 октябрь, 853 нче; 2012 ел, 9 апрель, 283 нче, 2012 ел, 25 сентябрь, 799 нчы, 2018 ел, 12 февраль, 76 нчы, 2020 ел, 26 октябрь, 958 нче, 2021 ел, 9 декабрь, 1209 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль законның 43 статьясы һәм Татарстан Республикасы Экология кодексының 137 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

Әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларына һәм су биология ресурсларына кертелмәгән хайваннар дөньясы объектларын аулау тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2010 ел, 22 апрель, 293 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 30 гыйнвар, 42 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларына һәм су биология ресурсларына кертелмәгән хайваннар дөньясы объектларын аулау тәртибе

1.1. Әлеге Тәртип «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль законның 43 статьясы һәм Татарстан Республикасы Экология кодексының 137 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә табигый ирек хәлендә яшәүче аучылык ресурсларына һәм су биологик ресурсларына кертелмәгән хайваннар дөньясы объектларын аулауга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

1.2. Әлеге Тәртипнең гамәлдә булуы хайваннар дөньясы объектларына кагылмый:

1) билгеләнгән тәртиптә аучылык ресурсларына һәм су биологик ресурсларына кертелгән;

2) Россия Федерациясенең Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән;

3) федераль әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрендә яшәүче;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләренә буйсынучы.

1.3. Хайваннар дөньясы объектларын чыгару фәнни, мәдәни-агарту, тәрбияви, рекреацион, эстетик максатларда, шулай ук ярымирекле шартларда һәм ясалма төзелгән яшәү тирәлегендә хайваннар дөньясы объектларын тоту һәм үрчетү максатларында башкарыла.

1.4. Хайваннар дөньясы объектларын чыгару түбәндәге таләпләрне үтәгәндә гамәлгә ашырыла:

1) хайваннар дөньясы объектлары төрләренең табигый популяцияләренә төзәтеп булмаслык зыян салуны башкармау;

2) хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеге җимерелүгә яисә начарлануга юл куймау;

3) хайваннар дөньясы объектларын чыгарганда хайваннар дөньясы объектларына физик һәм психик җәрәхәтләр ясауны булдырмый торган гуманлы ысуллар куллану.

2.1. Хайваннар дөньясы объектларын чыгару ел дәвамында рөхсәт ителә һәм Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан бирелә торган рөхсәт буенча башкарыла.

2.2. Көндезге ерткыч кошларны лачын аулау өчен алга таба куллану максатларында чыгару бер ел дәвамында оя кору чорыннан тыш ике кош алу яисә оядан кимендә бер кош баласын алу рөхсәт ителә.

2.3. Хайваннарның ояларын, өннәрен, сыену урынын, качу урыннарын, торак урыннарын җимерү, хайваннар дөньясы объектларын ярлы хәлдә һәм ярдәмсез хәлдә табу, шулай ук хайваннар дөньясы объектларын үрчүгә комачаулаучы башка гамәлләр тыела.

---